# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлегенең Камыллы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**12 ноябрь, 2022 ел.** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 10 сәгать 00 минутта 2022 елның 12 ноябрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән «Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

**а)** ***җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге*:**

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;

-җирлектәге торак пунктлар чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 50 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 28, бу 56 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында 28 катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлегенең Камыллы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче

балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме

**а) *җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге*:**

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;

-җирлектәге торак пунктлар чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту- соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштырырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Иске-Тәрбит авыл җирлеге Башлыгы В.Г.Тимофеев